| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.12.2018 Казан ш. № 10-185/кс

«Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе өчен эчә торган суга һәм су агызуга 2019-2023 елларга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе өчен, шушы карарның 1 нче кушымтасы нигезендә, календарь буенча бүлеп, эчә торган суга һәм су агызуга тарифлар билгеләргә.

2. Шушы карарның 1 нче пунктында билгеләнгән тарифлар 2019 елның 1 гыйнварыннан башлап 2023 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе өчен эчә торган суга һәм су агызуга 2019-2023 елларга, әлеге карарның 2 нче кушымтасына туры китереп, тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрларын билгеләргә.

4. Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесенә ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар

билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 19.12.2018 № 10-185/кс карарына 1 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе өчен эчә торган суга һәм су агызуга 2019-2023 еллар өчен календарь буенча бүленгән тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Ел | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб м. | Су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|---|
| | «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге | | | |
| 1 | «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе | | | |
| 1.1 | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде)* | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 19,97 | 16,72 |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 20,59 | 18,06 |
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 20,59 | 18,06 |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 21,84 | 18,54 |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 21,77 | 18,54 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 21,77 | 18,95 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 21,77 | 18,58 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 22,89 | 18,58 |
| | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 22,89 | 18,58 |
| | | 01.07.2023 башлап | 22,92 | 19,51 |

| №<br>п/п | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Ел | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб м. | Су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|---|
| | | 31.12.2023 кадәр | | |
| 1.2 | Бүтән кулланучылар (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелде) | 01.01.2019 башлап<br>30.06.2019 кадәр | 16,64 | 13,93 |
| | | 01.07.2019 башлап<br>31.12.2019 кадәр | 17,16 | 15,05 |
| | | 01.01.2020 башлап<br>30.06.2020 кадәр | 17,16 | 15,05 |
| | | 01.07.2020 башлап<br>31.12.2020 кадәр | 18,20 | 15,45 |
| | | 01.01.2021 башлап<br>30.06.2021 кадәр | 18,13 | 15,45 |
| | | 01.07.2021 башлап<br>31.12.2021 кадәр | 18,13 | 15,79 |
| | | 01.01.2022 башлап<br>30.06.2022 кадәр | 18,13 | 15,48 |
| | | 01.07.2022 башлап<br>31.12.2022 кадәр | 19,08 | 15,48 |
| | | 01.01.2023 башлап<br>30.06.2023 кадәр | 19,08 | 15,48 |
| | | 01.07.2023 башлап<br>31.12.2023 кадәр | 19,10 | 16,26 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын үтәү максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының 19.12.2018 № 10-185/кс
карарына 2 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе өчен 2019-2023 елларга эчә торган суга һәм су агызуга тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрлары

| № п/п | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Су югалту дәрәҗәсе | Электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе | | | | | | |
| 1.1 | Эчә торган су | 2019 | 1025041 | 1 | - | 7.2 | 0,775 |
| | | 2020 | 1049293 | 1 | - | 7.2 | 0,775 |
| | | 2021 | 1080352 | 1 | - | 7.2 | 0,775 |
| | | 2022 | 1112331 | 1 | - | 7.2 | 0,775 |
| | | 2023 | 1145256 | 1 | - | 7.2 | 0,775 |
| 1.2 | Су агызу | 2019 | 743 995,57 | 1 | – | - | 0,66 |
| | | 2020 | 761 598,50 | 1 | – | - | 0,66 |
| | | 2021 | 784 141,82 | 1 | – | - | 0,66 |

| № п/п | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Су югалту дәрәҗәсе | Электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| | | 2022 | 807 352,41 | 1 | – | - | 0,66 |
| | | 2023 | 831 250,04 | 1 | – | - | 0,66 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге